Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының
Татар Талкышы авыл җирлеге башлыгы
Карары

2020 елның 10 ноябре № 8

«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Чистай муниципаль районы Татар Талкышы авыл җирлегенең Кызыл Болгар авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Чистай муниципаль районының «Татар Талкышы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2020 елның 23 ноябрендә 15.00 сәгатькә авыл клубы бинасында Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Талкышы авыл җирлегенең Кызыл Болгар авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының беренче этабын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Татарстан Республикасы, Чистай районы, Кызыл Болгар авылы, Зеленая ур., 16а йорт.

2. 2020 елның 26 ноябрендә 15.00 сәгатькә авыл клубы бинасында Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Талкышы авыл җирлегенең Кызыл Болгар авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенының икенче этабын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Татарстан Республикасы, Чистай районы, Кызыл Болгар авылы, Зеленая ур., 16а йорт.

3. Гражданнарның этаплап җыенын үткәрү өчен Татарстан Республикасы Татар Талкышы авыл җирлегенең Кызыл Болгар авылында яшәүчеләр исемлеген 2 өлешкә бүләргә:
1)Урам:Зеленая;
2)Урам:Пионер.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2021 елда Чистай муниципаль районы Татар Талкышы авыл җирлегенең Кызыл Болгар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән үзара салым кертүгә, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарыннан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күпбалалы гаиләләрдән, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 700 сум күләмендә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризалашасызмы:

- чокырлы юлларны ремонтлау (вак таш сатып алу, китерү, салу, килешүләр буенча түләү)

«ЯКЛЫ» «КАРШЫ».

5. Җыенны оештыручы итеп Чистай муниципаль районының Татар Талкышы

авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

6. Чистай муниципаль районының Татар Талкышы авыл җирлеге башлыгының «Чистай муниципаль районының Татар Талкышы авыл җирлегенең Кызыл Болгар авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җыенын билгеләү турында» 2020 елның 30 октябрендәге 5 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

7. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләрне күпләп җыелган урыннарда, игълан итү стендларында һәм такталарында элү юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Чистай муниципаль районының
Татар Талкышы
авыл җирлеге башлыгы М.М. Вәлиев